Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР 7**

**01.04.2019 ел**

**«Ямбакты авыл җирлеге территоиясендә
санитар - экологик икеайлык
чистарту үткәрү турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 21.03 № 567-р күрсәтмәсе нигезендә, җирлек территориясен санитар чистарту мәсьәләсен хәл итү һәм аны халыкның санитар - эпидемиологик һәм экологик иминлегенә җавап бирүче халәткә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Ямбакты авыл җирлеге территориясен чистарту буенча 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр санитар - экологик икеайлык игълан итәргә;
2.Икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаб төзергә (1 нче кушымта)
3.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «икеайлык чорында» Ямбакты авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә санитария - экология хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар планын - расларга;
4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы " Ямбакты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларын бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Ямбакты авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе: И. Ә. Галәветдинов.

## ЧАРАЛАР ПЛАНЫ

Ямбакты авыл җирлегенең санитар-экологик хәлен ике ай эчендә (01.04.2019-31.05.2019) яхшырту өчен

| № | Чаралар | Җаваплы кешеләр | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | **Авыл чисталыгына җаваплы кешеләрне беркетү.** | **Ямбакты авыл җирлеге Советы депутатлары: (исемлек бирелә)** | 09.04.2019 кадәр |
| 2. | **Авыл җирлеге территориясен рөхсәтсез чүплекләрне ачыклау буенча тикшерү.** | **Шәйхетдинова Р. Ф. Ямбакты авыл җирлеге БК секретаре** | **апрель** |
| 3. | Рөхсәтсез чүплекләрне чыгару. Чүплектә тирес ташу | Галәветдинов И. А- Ямбакты авыл җирлеге башлыгы | даими |
| 4. | Ямбакты авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең шәхси секторында йорт яны территорияләре буенча рейдлар үткәрү» | Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләре | Атна саен |
| 5. | Оешмалар, учреждениеләр һәм урамнар территорияләрен чистарту буенча өмәләр оештыру. | Галәветдинова Ф. А..- мәктәп директоры; Шәфигуллин Р. Р..- авыл мәдәният йорты директоры. | апрель, май |
| 6. | Азат итүчегә һәйкәлнен җыештыру һәм ремонтлау. | Шәфигуллин Р. Р..- авыл мәдәният йорты директоры. | 01.05.2019 кадәр |
| 7. | Гагарин урамы, Камал урамы, Танино авылы, Сабанча авылы зиратлары территорияләрен төзекләндерү. | Авыл җирлеге башлыгы- Галәветдинов И. А.; мәчетнең имам-хатыйбы Гарифҗанов Р. Г. | май |
| 8. | Юл буе полосаларын, кюветларны, урман посадкаларын чүп-чардан чистарту. | Иҗтимагый хезмәткәрләр (исемлек теркәлә) | даими |
| 9. | Баганалар электр тапшыру линияләре агарту. | Иҗтимагый хезмәткәрләр (исемлек теркәлә) | апрель |
| 10. | Үләт базы территориясен җыештыру. | Галәветдинов И. А. - авыл җирлеге башлыгы. | май |
| 11. | Су башнясы территорияләрен җыештыру | сулыклар хезмәткәрләре | апрель, май |

Ямбакты авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: И. Ә. Галәветдинов.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯМБУХТИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЯМБУХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1637005552

Приложение № 1
к постановлению исполнительного комитета
Ямбухтинского сельского поселения
№ 7 от 01.04.2019 г.

**Состав**
**оперативного штаба Ямбухтинского сельского поселения по санитарной очистке территории Ямбухтинского сельского поселения на период двухмесячника**

| **№ п/п** | **Ф.И.О.** | **Должность** |
|---|---|---|
| 1 | Галяутдинов Ильшат Ахатович | глава Ямбухтинского сельского поселения |
| 2 | Шайхутдинова Рамзия Фоатовна | секретарь Ямбухтинского СП |
| 3 | Галяутдинова Фаиза Асатовна | директор Ямбухтинской СОШ |
| 4 | Мухаметшина Василя Магсутовна | Зав.ФАП |
| 5 | Шафигуллин Радиф Рафикович | Директор СДК |
| 6 | Хусаинова Гульфия Якуповна | депутат с.Ямбухтино |